күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

## Мәктәп яңалыклары...

4 нче чыгарылыш
27 нче декабрь

БУ САНДА:

| | |
|---|---|
| Яңа ел, белән! | 1 |
| Яңалыклар | 2 |
| Инша яздым, утырып... | 3 |
| Котлыйбыз! | 4 |




ЯНА ЕЛ!
Яңа еллар кил-
сен бәхет алып,
Яңа еллар кил-
сен елмаеп.
Күңелләрдә
мәңге шатлык
булсын,
Табыннар тулып
торсын!
Яңа ел белән!
Яңа ел белән!

# Алдынгылар….

Гыйлемле кешене элек-электән иң байга санаганнар. Шулай булмый мөмкин дә түгел, белем дә, саулык та сатып алынмый. Саулык һәм сәләт Аллахтан бүләк булса да, аларны саклар яки булдырыр өчен тырышлык та кирәк. Ялкаулыкны җиңеп, кулларыннан китап төшермәгән, интернеттагы файдасыз сайтларда азрак казынган малайлар-кызлар мәктәп күләмендә олимпиадаларда җиңү яулап, район күләменә чыктылар.

Вакытларын бушка уздырмауның нәтиҗәсе билгеле - алар Бөтен Рәсәй олимпиадасының муниципаль этабында фән олимпиадалары җиңүчеләр: Сафин Мөхәммәд (4 “А”, укытучысы: Зарипова И.В., математика)

Нургалиева Җәмилә (8 кл.,укытучысы: Вәлиуллина Ә.Ф., татар теле)

Призерлар:

Ногманова Азалия (8 «А», укытучысы: Володина Т.С., рус әдәбияты);

Сивкова Александра (6 «А», укытучысы: Дементьев А.Г., математика);

Морозов Никита (4 “А”, укытучысы: Зарипова И.В., математика)

Ситдикова Саида (4 “Г”, укытучысы:Тимрюкова Л.А., математика)

Зәйнетдинова Раяна (5 “Е”,укытучысы:Филиппова А.Р., инглиз теле)

Афәрин!

Кадерле кучыларыбыз! Сезгә региональ этапта уңышлар телибез!



Илһамият» халыкара сүз һәм вокал сәнгате буенча узган фестиваль-бәйгедә

5 нче сыйныф укучысы Мельникова Аделина сүз сәнгате буенча 2 нче урынга,





3 нче сыйныф укучысы Гайнетдинова Камалия вокал сәнгате буенча 3 нче урынга лаек булды.

Аделина һәм Камалияне котлыйбыз, киләчәктә дә зур уңышлар телибез!



Республика күләм Парламент дәресе бәйгесендә “Парламент, җәмгыять һәм мин” дигән темага язган иншасы белән җиңү яулаган Каюмова Ирина. Афәрин!





## «Йолдызлар атылу» бәйгесеннән....



Укытучылар! Белем бирүче, белем дөньясына сәяхәткә алып кереп китүчеләр...

Алар -үрнәк, алар -алдынгылар!

Укучыларны фән дөньясына алып керүчеләр дә, алар!

Дәрес укыту, дәфтәр тикшерү, киләсе дәресләргә әзерләнү….Аларның хезмәте санап бетерерлек түгел…

Беләсезме? Алар әле җыр-биюгә, нәфис сүз сәйләргә дә бик оста!

Район күләмендә уздырылган “Йолдызлар атылу” бәйгесендә 2 нче урынны яуладылар.



Хөрмәтле укытучыларыбыз!

Без сезгә карап сокланабыз! Мельникова Аделина, газета хәбәрчесе

# Инша яздым, утырып...



Елның иң матур вакыты, ул, мөгаен, ак кыштыр. Салкын булса да аны, яратмаганнар юктыр... Кыш... Салкын булсаң да, нинди ак, сихри матур син... Һәрбер кеше аны үзенчә кабул итә, ярата. Яратып кына калмыйлар, укучылар бу ел фасылы турында үзләренең хисләрен дә белдерәләр.

Яратам кыш айларын.

Кышны бик зарыгып көтеп алам мин. Зәмһәрир суыклары булса да, яратам бу ел фасылын. Суык көннәрдән күп кеше зарлана, туңа. Ә мин, киресенчә, рәхәтләнеп уйныйм. Суыкта бит тимераякта, чаңгыда шуулары да икенче, жепшек көн түгел инде! Шулай да суыкка түзә алмыйча, шарт-шорт итеп агач коймалар ярыла. Телеграф чыбыкларына тезелешеп утырган чыпчыклар, йоннарын кабартып, кеч-кенә тупка охшап калалар. Иртәнге кояш нурында агач-куакларны сарган бәс жем-жем килеп ялтырый. Мондый матурлыкны берни белән дә алыштырып булмый. Тәрәзә пыялаларына андый итеп рәсемнәрне бары тик зәмһәрир суык кына ясый ала. Урамнан өйгә кергәндә ул гына сиңа ияреп кереп, өйнең түренә житә. Һәр ел фасылының үзенә генә хас кабатланмас матурлыгы бар.

Мәхмүтова Мәликә , 5 “Е” сыйныф укучысы

Туган ягымда кыш.

Ак тунлы, салкын бураннары белән кыш аяк басты туган ягыбызга. Салкыннан кешеләрнең борыннары, колаклары кызарды. Ә мин куанып, кәшәкә күтәреп, шугалакка йөгердем. Минем өчен кыш ул – шома боз өсте. Карлы тауларны, чана-чаңгыларны бик еш төштә күрәм. Әле көткән кар бик әз, йомшак, юаш кына ята. “Яңгыр яу, яу, майлы ботка бирермен, майлы ботка казанда, тәти кашык базарда” дип жырлый торган жырны яңача жырлыйм: “Кар яу, яу, чаңгыларым майлаган, конькиларым әзерләнгән”.

Хәйриев Самат,5“Д” сыйныфы укучысы

Кыш безнең белән уйный.

Кыш бик матур. Аның шуклыклары да күп. Кыш үзе генә түгел, аның жиле дә шаяра. Ул күзне ачып булмаслык итеп карны тузгыта, бураннар чыгара. Кышның жиле безгә эш тә ясый. Йөри торган юлларга кар өя. Жил шундый шуклыклар эшли, ә кыш үзе нишли удип йлыйсыз? Кыш кешеләрнең битләрен кызарта. Колагың башлыктан әз генә чыкса, колак очларын өшетә һәм син үтә күренмәле алка таккан кебек буласың. Кыш көзге яңгырлардан юлда юка боз катыра. Аны кар белән каплый. Боз *күренми*, карга басам дип, бозга басып, таеп егыласың. Шук кыш тәрәзәләргә язны, ужәйне искә төшереп, аларга багышлап бизәкләр ясый. Кыш никадәр шук булса, без аны шулкадәр ныграк яратабыз.

Эльза Гаврилова, 5 “Е” сыйныфы укучысы

Кыш төрлечә була.

Кыш үзенекен итә. Ул бик суык та, шаян да була белә. Колакны, битне чеметтерә. Матур-матур рәсемнәр ясый. Әйтерсең, ул – рәссам. Кыш боларның барысына да ничек өлгерә икән? Болар өстенә ул безгә таулар өеп куя. Таулары шундый биек, өй түбәләренә хәтле менә. Балалар тимераякта шусын дип бозлар катыра, кар бабай ясарга дип карлар яудыра. Кыш шулай ук агачларны да онытмый, башларына ак бүрек кидерә. Зифа каеннар да кар кызыдай сылу булып, басып торалар.

Кышның эше күп. Ул карларын яудырып

Бөтен жирне акка төрә.

Гаврилова Эльза,5 “Е” сыйныфы укучысы

күп профильле
181 нче мәктәп

Тулпар урамы, 2нче йорт

Телефон: 89050229576

Эл. почта: gabdullazyanova1979@mail.ru

Безнең девизыбыз:

«Без-өлгерләр!»

Хөрмәтле укытучыларыбыз!

Гатин Илнур Зөлфәт улы (01.01.1975)

Зарипова Инна Владимировна (02.01.1972)

Гайнетдинова Снежана Вячеславовна (02.01.1986)

Марварова Гөлнара Дамир кызы (10.01.1980)

Юнусова Римма Дамир кызы (21.01.1983)

Сезне туган конегез белән ихлас котлыйбыз.Бәхетле, озын гомер телибез!

Озын гомер, ак бәхетләр

Сезгә бездән теләкләр.

Шушы кызыл розалар,

Булсын Сезгә бүләккә!



**Хөрмәтле укытучылар, кадерле укучылар!**

Менә 2 нче чирек тә ахырына якынлашты.

Сезне киләчәк Яңа ел бәйрәме белән котлыйбыз.

Яңа ел сезгә уңышлар алып килсен! Теләгән барлык теләкләрегез тормышка ашсын!

Изге теләкләр белән,

газета хәбәрчеләре




Редколлегия:
Мәхмүтова Мәдинә, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камилия, Вәлиева Диләрә,Корчагина Яна, Хәсәнова Адилә, Мельникова Аделина
Җитәкчесе:А.Ф.Габдуллаҗанова